**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

г.Казань

**22.12.2015** **№ 01-02/821**

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының “Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында вазыйфалары коррупция куркынычы алдында торган һәм дәүләт граждан вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфалары исемлеген раслау турында” 2015 елның 11 мартындагы 01-02/170 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының “Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында вазыйфалары коррупция куркынычы алдында торган һәм дәүләт граждан вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2015 елның 11 мартындагы 01-02/170

номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Боерыкның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенә (Т.Ю.Латыева) Вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфаларны биләүче дәүләт граждан хезмәткәрләренә, эштән киткәндә, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясында каралган чикләүләр, бурычлар һәм җаваплылык мәсьәләләренә ачыклык кертергә.»;

Боерык белән расланган Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында вазыйфалары коррупция куркынычы алдында торган һәм дәүләт граждан вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфалары исемлегенең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «җитәкчеләр» категориясендәге вазыйфаларның әйдәп баручы төркеме:

финанс бүлеге мөдире урынбасары;

кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге мөдире урынбасары;

хокукый экспертиза һәм нормалар иҗат итү бүлеге мөдире урынбасары;

хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлеге мөдире урынбасары;

җирле үзидарә һәм муниципаль регистр алып бару өлкәсендә норматив хокукый эш бүлеге мөдире урынбасары;

җәмәгать судьялары эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге мөдире урынбасары;

мәгълүмати-аналитик эшчәнлек, координацияләү һәм планлаштыру бүлеге мөдире урынбасары;

балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итү секторы мөдире;

түләүсез юридик ярдәм күрсәтү секторы мөдире.».

2. Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлегенә (Сафин А.Г.) әлеге боерыкны “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрдәге Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталындагы Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы сайтының “Коррупциягә каршы тору” бүлегенә урнаштырырга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Министр Л.Ю.Глухова